**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИЛЯР-ОЗЕРО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**«20» май 2022 ел** **№ 9**

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авыл җирлеге Советының 2021 елның 28 июлендәге 21 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә яшел үсентеләрне кисү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2008 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Биляр-Озеро авыл җирлеге Уставы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Нигезләмәнең 4.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авыл җирлеге Советының 2021 елның 28 июлендәге 21 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә яшел үсентеләрне кисү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«4.2. Биляр-Озеро авыл җирлеге территориясендә агач һәм куаклар кисү Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан комиссия тикшерүе акты нигезендә бирелә торган рөхсәт нигезендә 17 эш көне эчендә башкарыла».

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://nurlat.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авыл җирлеге Советының Сәламәтлек саклау, санитар һәм экологик эш буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Биляр-Озеро авыл җирлеге
Советы рәисе В.С.Оренбургов